СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 31 » гыйнвар 2017 ел** **№ 103**

**«Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 329 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2016 елның 30 июнендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законга һәм "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Арча районы Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 329 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**а) 7.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«7.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә, шулай ук яллаучы (эш бирүче) вәкиленең тиешле карары булганда - белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.»;

**б) 7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«7.2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типлаштырылган квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен югары белем булу; вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы.

Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.

3) өлкән һәм кече төркемнәрнең муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

5) муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең дәүләт граждан хезмәте Вазыйфаларында һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт Вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәте Вазыйфаларында эш стажы да исәпкә алына.

6) контракт буенча билгеләнә торган муниципаль районның җирле администрациясе башлыгы вазыйфасына кандидатларга карата өстәмә таләп белән кимендә биш ел идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе булу билгеләнә. Әлеге өлештә җитәкче, җитәкче урынбасары, дәүләт органы, муниципаль орган вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләренең вазыйфаларында эшләү әлеге өлештә идарә эшчәнлеге дигәндә аңлашыла.»;

**в) 9.1 пунктының 8.1 пунктчасында үз көчен югалткан дип танырга;**

**г) 10 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

4) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны узуга яисә аны үтүгә комачаулый торган авыру булу;

**д) 10.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:**

«11) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.1 статьясында каралган белешмәләрне тапшырмау;

**е) 11 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«4) вазыйфаи торышына бәйле рәвештә яисә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссудалар, хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләү) алырга. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә алынган бүләкләр муниципаль милек дип таныла һәм муниципаль хезмәткәрләргә акт буенча җирле үзидарә органына, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенә тапшырыла, моңа Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән очраклар керми. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә алган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин»;

**ж) 12 пунктның 12.1 һәм 12.2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«12.1. Әлеге нигезләмә максатларында «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 10 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән «мәнфәгатьләр конфликты» төшенчәсе кулланыла.

12.2. Әлеге Нигезләмә максатлары өчен «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән «шәхси кызыксынучанлык» төшенчәсе кулланыла.

з) 23 пунктта «җайга салына» сүзләреннән соң «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон» сүзләрен өстәргә;

и) 11 пунктның 11.3 пунктчасында «акцияләр белән» һәм «акцияләр» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советы рәисе урынбасарына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе — И.Г. Нуриев